ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.11.2022 Балык Бистәсе штп. № 328пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 25.11.2021 №254пи карары белән расланган каникул вакытында балаларның ялын оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 15.08.2022 ел, №1415 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарының 1 пунктындагы а пунктчасы нигезендә, муниципаль норматив хокукый актларны Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 25.11.2021 №254пи карары белән расланган каникул вакытында балаларның ялын оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба-Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.2.1 пунктның 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Формалаштырылган гарызнамәне формат-логик тикшерү, мөрәҗәгать итүче электрон формадагы һәр юлны тутыру процессында орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, Бердәм портал тарафыннан автоматик рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан гарызнамәнең электрон формасында дөрес тутырылмаган юл ачыкланганда мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында электрон формада мәгълүмати хәбәр җибәрелә.”.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе И.М. Садыйковка йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р.Л. Исланов